Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
**«Каракашлинская основная общеобразовательная школа»**
**Ютазинского муниципального района Республики Татарстан**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДАЮ |
| --- | --- | --- |
| Протокол заседания ШМО учителей начальных классов | Заместитель директора по учебной работе | директор МБОУ « Каракашлинская ООШ» |
| от 22.08.2019 г. №1 | _____Мугтасимова З.Н. | _____Ахметова Э.Ф. |
| Руководитель | «23» августа 2019 г. | Приказ №106 от |
| _____Нагимова И.С. подпись | | « 23 » августа 2019 г. |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**
учебного предмета
**«ПО РОДНОМУ (ТАТАРСКОМУ) ЯЗЫКУ»**

для начального общего образования
Классы: 1 - 4

Срок освоения программы: 4 года
Период освоения: 2019-2020 - 2022-2023

Составители: Мугтасимова З.Н., Ахметова Э.Ф.,
Мурасова Г.Р., Нагимова И.С. учителя начальных классов

ПРИНЯТА
на заседании
педагогического совета
протокол № 1 от
«23» августа 2019 г.

2019

## Предметның укыту планындагы урыны

Татар теле “Татар теле” белем бирү өлкәсенә карый, гуманитар фәннәр циклына керә.

Программа 1-4 нче сыйныф укучыларына 68 сәгатькә исәпләнеп төзелгән; атнага 2 сәгать вакыт бирелә. 2017/2018 уку елында программага үзгәрешләр кертелү сәбәпле, һәр сыйныф өчен сәгатьләр саны кыскартылган (һәр сыйныф өчен атнага 2 сәгать исәбеннән) үрнәк календарь-тематик планнар тәкъдим ителә. Шуны истә тотарга киңәш ителә: программаның эчтәлеге һәм дәресләрнең максаты үзгәрешсез кала.

**Бирелгән программа буенча укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр.**

**1 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**

**Укучыларның беленмәнә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр.**

**Әзерлек чоры ахырына балалар өйрәнәчәк**:

- Элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны аңлый, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын атый һәм формалары буенча аера белергә;.
- Рәсем, график модель яки тиешле фишкалар кулланып, беренчедән, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2 — 4 сүздән торган җөмләләр һәм 3 — 4 җөмләдән торган хикәя төзи; икенчедән, парта артында дөрес утыра һәм язма әсбаплардан дөрес файдалана, алгоритм буенча яки тактлап язма хәрефләрнең барлык элементларын да дөрес яза белергә тиешләр.
- Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре.Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү.
- Уку дәресләрендә элемент-өлгеләр ярдәмендә басма хәрефләрне төзү күнегүләре. Балалар хәтерендә барлык басма хәрефләрнең күрмә образларын формалаштыру.
- Балалар хәтерендә язма баш һәм юл хәрефләренең төгәл күрмә-хәрәкәтле образларын формалаштыру. Бу хәрефләрне алгоритм һәм тактлап (санап) язу технологиясен камилләштерү.

**Әлифбаны (грамотага өйрәтү) бетергәндә укучылар түбәндәгеләрне белергә тиеш:**

- укырга – язарга өйрәтү барышында гамәли алынган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне гомумиләштерү, системалаштыру;
- сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан юлга күчерү;
- язуга карата төп гигиена кагыйдәләрен үтәү;
- хәрефләрнең график яктан дөрес язылышын, сүздә аларны тоташтыру ысулларын;
- хәрефләрне дөрестоташтырып, ритмлап иҗекләр, сүзләр, кечкенә җөмләләр язу;
- кечкенә текстларны тактадан, дәреслектән дөрес итеп (иҗек һәм хәрефләрне төшереп калдырмый, урыннарын алмаштырмый, хәреф формаларын бозмыйча), сүзләп күчереп язу;

- әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрдән төзелгән җөмләләрне ишетеп язу (диктант);

- **э,о,ө,й,е,ю,я** хәрефләре, **йө,йо** кушылмалары булган сүзләрне дөрес язу; кеше исем, фамилияләрен, хайван кушаматларын, җөмлә башындагы сүзләрне баш хәрефтән язу;
- җөмлә ахырында нокта кую;
- билгеле бер темага һәм рәсемнәргә карата җөмләләр уйлау;
- сюжетлы рәсемнәр, балаларның күзәтүләре буенча укытучы куйган сораулар ярдәмендә телдән кечкенә хәкәяләр төзү.

**1 классны тәмамлаганда укучылар белергә тиеш:**

- татар телендәге барлык аваз һәм хәрефләрне гамәли танып белергә, аваз белән хәрефнең төп аермасын практик аңлауга ирешергә тиеш;
- сүзләрне авазларга таркату, авазларны сүздәге тәртиптә әйтү;
- сүзык һәм тартык авазларны һәм аларның хәрефләрен аерып таный белү;
- калын һәм нечкә сузыкларны дөрес әйтү;
- сүзләрне иҗекләргә бүлү;
- җөмләләрне сүзләргә таркату;
- баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу;
- басма, язма хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу;
- әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрне, шундый сүзләрдән төзелгән 3-5 сүзле җөмләләрне ишетеп дөрес язу;
- җөмләнең беренче сүзен баш хәреф белән башлап, җөмлә беткәч, нокта куеп язу;
- телдән 4-5 җөмләле кечкенә хикәяләр төзү;

**Беренче сыйныф укучыларының белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр.**
**Төп чор** ахырына балалар өйрәнәчәк**:**
1. Татар теленең авазларының сузык (ачык авыз символы белән бирелгән), ягъни җырлана торган аваз һәм тартык, ягъни җырланмый торган; әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала / ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә- калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;
- сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;
- сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;
- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен;
- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүләрен, ярдәмче сүзләр сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын;
- әйтмә сөйләмнең текст һәм җөмләләргә бүленүен, аларны график сурәтләп булу мөмкинлеген;
элемент-сызыклар һәм элемент-өлгеләрнең басма һәм язма хәрефләрнең график системасының структур (төзелеш) берәмлекләре булуын;
- һәр басма һәм язма хәреф формасының тиешле урын-сан мөнәсәбәтендә урнашкан элементлардан торуын аңлый белергә тиеш.
2. Укучылар сүз башыннан башлап, андагы һәр авазны көчлерәк итеп билгели бара, берсен аерып алып аңа характеристика бирә;

- анализ вакытында тартыкларның яңгырау-саңгыраулыгын билгеләү алымнарын куллана;
- сүзне иҗекләргә бүлә;
- схемалардан сүзнең аваз язылышын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп укый;
- схемалардагы һәм «Әлифба» текстларында бирелгән хәреф язуын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп укый;
- сүзнең аваз формасын шартлы график формадан хәреф формасына һәм киресенчә үзгәртә;
- элемент-шаблоннар нигезендә басма һәм язма хәрефләрне төзи һәм анализлый;
- аерым график биремне үтәү дәвамында дөрес итеп утыра һәм язма әсбаплардан файдалана ала;
- билгеле бер алгоритм буенча хәрәкәт элементлары нигезендә хәрефләр яза;
- иҗекләрдә һәм сүзләрдә тоташтыруның өч алымын үти;
- тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшарта;
- күчереп язганда һәм диктант вакытларында җөмләләрне һәм үз исемнәрен дөрес яза;
- бизәк-бордюрлар ясый ала белергә тиешләр.

Алгоритм буенча сүзләрдә язма хәрефләрнең һәм аларны тоташтыру сызыкларын язу технологиясен ныгыту.
Тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшару халәте белән чиратлаштыра белү.
Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу, әйтеп яздыра торган текстны язу.
Грамотага өйрәтүнең **әлифбадан соңгы чоры**нда беренче сыйныф укучылары өйрәнәчәк:
1. Туган телнең сөйләм төзелешен аңлый, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләрен образлы күзаллый;
- татар алфавиты басма һәм язма хәрефләренең график системасын;
- һәр хәрефнең элемент формаларын;
- дөрес утыру һәм язма әсбапларны куллану кагыйдәләрен белергә тиеш.
2. Һәр укучы үзенә генә хас темпта басма һәм язма текстларны офоэпик нормаларга туры китереп укый;
- текстның аерым бер өлешләрен сөйли (2 — 3 җөмлә белән) ;
- укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җавап бирә;
- тыңланган текстка исем куша;
3. О, ө хәрефләрен беренче иҗектә генә язу;
- әйтмә һәм язма сөйләмне тел берәмлекләренең төзелеше турында беренче сыйныф укучыларында формалашкан күзаллау нигезендә анализлау һәм тиешле символлар белән модельләштерү;
- тыныш билгеләренә игътибар итеп, иҗекләп, орфоэпик, бәйләнешле итеп уку алымнарын куллану;
- хәрефләрне язуда тоташ һәм тиз итеп язу алымнарын тормышка ашыру;
- татар теленең позицион принцибына нигезләнеп, [гь] [кь] авазларын язуда белдерү турында үзләштергән белем һәм күнекмәләрен уку эшчәнлегендә һәм көндәлек тормышта кулланырга өйрәнергә тиешләр
- сүзләрне авазларга таркату; авазларны сүздәге тәртиптә әйтү; сузык һәм тартык авазларны һәм аларның хәрефләрен аерып таный белү; калын һәм нечкә сузыкларны дөрес әйтү; сузык аваз һәм аларның хәрефләренә карап, калын һәм нечкә әйтелгән сүзләрне тану; сүзләрне

иҗекләргә бүлү; җөмләләрне сүзләргә таркату. Баш һәм юл хәрефләрен, аларны оташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу. Басма, кулдан язылган хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу. Әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрне, шундый сүзләрдән төзелгән 3-5 сүзле җөмләләрне ишетеп язу. Җөмләнең беренче сүзен баш хәреф белән башлап, җөмлә беткәч, нокта куеп язу.

Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:
- телдән 4-5 җөмләле кечкенә хикәяләр төзү. Сыйныфта телдән җыр, шигъри куплетлар, мәзәк, әкият уйлап чыгару.
- төрле методик шартларда: 1) басма яки язма текстны күчереп язганда, 2) хәтер буенча яки 3) укытучы әйтеп яздырган вакытта, үзләштерелгән алгоритмга туры китереп аерым да, җөмлә эчендә дә сүзләрне өзмичә язу күнекмәләрен үзләштерә һәр укучы, шәхси мөмкинчелеген истә тотып, язу темпын арттыра белү кебек эш төрләрен башкара белергә тиеш.
-график хаталарны төзәтү һәм каллиграфик язу сыйфатын камилләштерү эшләре.
-тизләтелгән темпта язу шартларында график грамоталылыкны һәм каллиграфик сыйфатны формалаштыру.

**2 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**

**Укучылар белергә тиеш :**

- кушма сүз, парлы сүз; тамыр һәм ясалма сүзләр;
- өйрәнелгән сүз төркемнәрен һәм аларның билгеләрен : исем, фигыль, сыйфат, зат алмашлыклары, алмашлык, кисәкчә, бәйлек;

**Укучылар башкара алырга тиешле эшләр:**

- -сүзләрне, җөмләләрне, 35-40 сүзле текстны, хәрефләрен бозмыйча, төшереп калдырмыйча, хәреф өстәмичә, урыннарын алыштырмыйча, аңлаешлы, пөхтә итеп, каллиграфик дөрес язу;
- -сузык һәм тартык авазларны, калын (нечкә) сузыкларны икеләнүсез аеру; өйрәнелгән теориягә таянып, аларга анализ ясау, бирелгән аваз схемасына, характеристика тиешле авазлар, сүзләр сайлау;
- -сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм, иҗекләп, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләренең катгый булмавын аңлау (аларның вариантларын белү);
- -сүздә шул хәрефләрнең эшен, вазыйфасын аңлату;
- -өйрәнелгән сүзләрдә калын(нечкә) тартыкларны сузык аваз хәрефләре яки ь, ъ белән күрсәтү;
- -кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга атамаларын, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу;
- -е, в, г, й, к, н, ң, о, ө, х, һ, э, ю, я хәрефләре, ый, йо, йө кушылмалары булган сүзләрне дөрес язу;
- -янәшә килгән бертөрле ике тартык аваз хәрефләре булган әллә, кәккүк, Габбас кебек сүзләрне, нечкә (калын) аеру билгесе кергән гади, программада булган сүзләрне дөрес язу һәм юлдан-юлга күчерү;
- -сүзгә фонетик анализ ясау:иҗекләргә бүлү, авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес итеп әйтеп, хәрефләрен атап чыгу, сузык (тартык) авазларны билгеләү, сузыкларның калын(нечкә) төрләрен аеру;
- -үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштырып төзәтү;

- -сүзләргә дөрес сорау кую һәм шуның нигезендә предметны, предметның эш һәм хәрәкәтен, билгесен белдергән сүзләрне таба белү, кем? нәрсә? сорауларына җавап биргән сүзләрне аера белү;
- -җөмләнең баш кисәкләрен табу, җөмләдәге сүзләр бәйләнешен билгеләү; җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, әйтелү максатына карап, җөмлә ахырында нокта, сорау билгеләрен куеп яза белү;
- -уку, уеннар, көндәлек тормыш, җәнлекләр, кош-кортлар турындагы темаларга 4-5 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп сөйләү һәм язу;

-сүзлекләрдәге сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: аваз, авыз, авыл, бәрәңге, бияләй, борын, вакыт, гомер, гыйнвар, дөрес, дүшәмбе, елга, җавап, җиңел, җомга, җөмлә, җылы, йөрәк, караңгы, көньяк, кыңгырау, маңгай, Мәскәү, муен, оныкˏ оя, пәнҗешәмбе, савыт, сәгать, сәлам, сеңел, сишәмбе, тавык, тавыш, тәмле, төньяк, уен, уңыш, хайван, хөрмәт, һава, һаман, чаңгы, чәршәмбе, чия, шәһәр, шуа, эссе, юан, якшәмбе.

**Шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләр**

Шәхси нәтиҗәләр:
- туган илгә карата шәхси караш булдыру;
- чын кеше сыйфатлары булдыру;
- мөстәкыйльлелек һөм җаваплылык үстерү;
- этик хисләр, мөлаемлылык үстерү;
- рухи-әхлакый идеалларына китерү.
- олылар белән хезмәттәшлек;
- аралашу культурасы күнекмәләре .

Метапредметлы нәтиҗәләр:
- аң -белем үстерү;
- проблемаларны мөстәкыйль рәвештә таба алу;
- эзләнү юлларын һөм нәтиҗәләрен ачыклау;
- логик фикерләү:чагыштыру, синтез, анализ ясый белү;
- конфликтлы ситуацияләрдән чыгу юлын табу;
- укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү;

Предметлы нәтиҗәләр:
- Россиядә күп милләт халыкларының төшенчәсен бирү;
- татар теленең төп төшенчәләр буенча башлангыч белем ( фонетик, лексик, грамматик);

- татарча югары сөйләм культурасыформалаштыру;
- туган телнең орфоэпик, лексик, грамматик төшенчәләре;
- сүз турында башлангыч төшенчәләр формалаштыру;
- уку, язу гамәлләре формалаштыру;
- сүзгә фонетик анализ ясый белү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**
- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**
-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:**
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларың/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**
- тормыштәҗрибәсенкуллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

**3 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**

. Белем алуның планлаштырылган нәтиҗәләргә түбәндәге төгәл билгеләнгән төп таләпләр куелды:
- **шәхси нәтиҗәләр** (баланың шәхси сыйфатлары, белем алуга әзерлеге һәм белем дәрәҗәсен , танып белүен үстерүгә сәләтле булуы);
- **предметара нәтиҗәләр** (баланың белем алуга сәләтен һәм алган белемнәрен практикада куллана белү осталыгын булдыручы универсаль уку гамәлләре );
- **предмет нәтиҗәләре** (уку предметын өйрәнү барышында яңа белемнәр алуда, аларны куллануда укучылар тарафыннан үзләштергән тәҗрибә)

Татар теледәресләрендә укучы шәхесен үстерүдә нәтиҗәләргә ирешү өчен тәп педагогик мәсьәлә булып балалардa**универсаль уку гамәлләрен** (УУГ) формалаштыру тора. Универсаль уку гамәлләрен өйрәнү укучыларга яңа белемнәрне уңышлы үзләштерергә, танып белүнең төрле өлкәсендә ориентлашырга, белем алуга теләк тудыруга мөмкинлек бирә.

Федераль дәүләт стандартлары түбәндә чагылдырылган планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүгә ориентлаша.

**Шәхси нәтиҗәләр:**

1) Туган республикага, туган илгә, халкына, ил тарихына карата гражданлык нигезләре, үз милләтен ярату, татар булуы белән горурлану хисләре формалаштыру;
2) табигать, халык, культура, дин төрлелеген берләштергән дөньяга социаль караш формалаштыру;
3) башка халыкларның культурасына, тарихына хөрмәтле караш, башкалар фикеренә карата түземлелек формалаштыру;
4) укучының тоткан урынын, укучы ролен кабул итү, укуга карата кызыксыну уяту, укуның шәхсән мәгънәсен аңлауны формалаштыру;
5) әхлакый нормаларны кузаллауга нигезләнеп, укучының үз эшләгән эшләре өчен шәхси җаваплылыгын, мөстәкыйльлеген үстерү;
6) эстетик ихтыяҗ һәм хис формалаштыру;
7) башкалар хисен аңлау, кайгырта белү, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, әхлакый хисләрен үстерү;
8) балаларның дуслары, олылар белән хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру, конфликтлы ситуацияләрне булдырмау һәм алардан чыгу юлларын таба белүләрен үстерү;
9) куркынычсыз һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, төрле тормыш ситуацияләренә һәм әдәби әсәрләрдәге геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
10) иҗади хезмәткә, эшнең нәтиҗәсенә мотивация булдыру, материаль һәм рухи байлыкларга сак караш формалаштыру.

**Предметара нәтиҗәләр** укучылар тарафыннан үзләштерелгән регулятив, танып белү, коммуникатив универсаль уку гамәлләрен чагылдыралар.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

1) эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү;
2) укытучы ярдәме белән уку проблемасын табу һәм формалаштыру;

3) укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
4) укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;
5) эш барышында гади генә эш кораллары белән эш
итә белү (линейка, карандаш, бетергеч...) һәм өстәмә чаралар (информацион һәм коммуникацион технологияләр, белешмә әдәбият һ.б.) куллана белү;
6) эш сыйфатына бәя бирә белү;
7) уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый һәм ул ситуациядән чыгу юлларын таба белү.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

1) дәреслек белән эш итә белү;
2) хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку;
3) этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку;
4) текста очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсенә төшенү;
5) текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү;
6) укытучының сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү;
7) предметларны чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү;
8) укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген кыскартып яки, тулыландырып сөйли белү;
9) уку мәсьәләсен чишүдә нинди информация кирәген мөстәкыйль ачыклау;
10) уку мәсьәләсен чишүгә кирәкле булган сүзлекләрне, белешмә материалларны, энциклопедияләрне, электрон дискларны, Интернетны мөстәкыйль таба белү;
11) уку барышында анализ (таркату) һәм синтез (берләштерү) гамәлләрен башкара белү;
12) фикерләүнең логик чылбырын төзи белү;
13) алынган мәгълүматны таблицалар, схемалар, конспект ярдәмендә күрсәтә белү;
14) текст эчтәлеге буенча гади план төзи белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

1) дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү;
2) үз фикерләрен телдән, яки язмача җиткерә белү;
3) укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
4) сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү;
5) башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
6) текстны укыганнан соң «автор белән диалог» алып бару (әсәрдә автор әйтергә теләгәнне таба белү).

**Предмет нәтиҗәләрен** чагылдыра**:**

1) уку предметының эчтәлеге, максаты;
2) дәреслектәге шәхси, регулятив, танып белүгә, коммуникатив, предмет нәтиҗәләренә юнәлтелгән продуктив биремнәр.

**4 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**
**Укучыларның белем һәм күнекмәләренә төп таләпләр**

**Укучылар белергә тиеш:**

-сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр һәм кушымча, ясагыч кушымча, төрләндергеч кушымча;
- сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль, кисәкчә, бәйлек, рәвеш.
- җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр, җөмләнең иярчен кисәкләре

**Укучылар башкара алырга тиеш:**

-үтелгән орфограммалар (калын һәм нечкә сузыклар, яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парсыз тартыклар, нечкәлек һәм аеру билгеләре, кушма һәм парлы сүзләр, тамырда авазлар чиратлашуы, кисәкчәләр) кергән 75-80 сүзле текстны, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен куеп, тиңдәш кисәкләр янында тиешле тыныш билгеләрен дөрес куеп диктант итеп язу.
-текстларны грамоталы һәм каллиграфик дөрес күчереп язу.
- сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү(тамыр һәм кушымчаларны аеру, кушымчаларның төрен билгеләү, тамыр, ясалма, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү).
- сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен тану, аеру (исемнең санын, килешен, фигыльнең затын, заманын);
- берлек сандагы исемнәрне килеш белән төрләндерү
- фигыльне заман формаларына куя белү.
-текстта синонимнарны һәм антонимнарны таный, сөйләмдә куллана белү.
-сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләрнең бәйләнешен билгеләү, сүзтезмәләрне аеру; сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне аеру.
- җөмлә тикшерү (төрен билгеләү, баш һәм иярчен кисәкләрне аера белү)
- бергәләп төзегән план буенча 90-95 сүзле изложение язу.
- текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү.
- текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, кызыл юлны саклау.
- текстның мәгънәле кисәкләре, җөмләләр арасында бәйләнеш булдыру.
- темасыннан яки төп фикереннән чыгып, текстка исем кую.
- хикәяләү, тасвирлау һәм фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү.
- шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып (алдан әзерлек белән), сочинение язу.
- фикер йөртү характерындагы җавап төзеп әйтү.

**4 нче сыйныф ахырына универсаль уку гамәлләре формалаштыру программасын үзләштерү буенча планлаштырыла торган нәтиҗәләр**

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен өйрәнү нәтиҗәсендә укучыларда белем алу осталыгы нигезе буларак **танып белү, коммуникатив, регулятив һәм шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре формалашачак.**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

• мөһим бәйләнешләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштырырга;
• күнегүләрне мөстәкыйл эшләү алымнарын үзләштерергә;
• тәкъдим ителгән план буенча телдән аңлатырга;
• материаль объект, таблица, рәсем, схемалар, сүзлекләр кулланырга;
• бирелгән алгоритм буенча күнегүләр башкарырга;
• фикерләүдә логик чылбыр төзергә;
• уку мәсьәләләрен модельләштерүдә билгеләр (символлар) кулланырга.

Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:

• интернетны кулланып, мәгълүмат эзләргә;
• мөстәкыйль рәвештә нигезләмә һәм критерийлар сайлап, чагыштыру, сериация һәм классификация башкарырга;
• сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләр урнаштыруны үз эченә алган логик хикәяләү төзергә.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

• партадаш күрше белән яисә төркемдә хезмәттәшлек итәргә;
• нинди дә булса предмет яисә объектка төрле карашлар булу мөмкинлеген аңларга;
• килешергә һәм уртак эшчәнлектә гомуми чишелешкә килергә;
• сораулар формалаштырырга.

Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:

• сораулар ярдәмендә партнердан өстәмә мәгълүмат алырга;
• монолог төзергә.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

• таблица буенча кагыйдәнең дөреслеген тикшерергә;
• гамәлләрне таләп ителгән вакытта башларга һәм тәмамларга;
• кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга ияреп гамәлләр кылырга;
• максатка кагылышсыз гамәлләрдән тыелырга;
• сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштырырга.

Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:

• партадаш күршең белән хезмәттәшлектә яңа уку мәсьәләләрен куярга;

• уку эшчәнлегенең үзең өчен әһәмиятен, мәгънәсен һәм сарыф ителгән вакытны, көчне бәяләргә;
• ирешеләчәк нәтиҗәне алдан фаразларга;
• яңа уку мәсьәләсен чишүгә керешкәнче үз мөмкинлекләреңне мөстәкыйль бәяләргә.

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре**

Укучыларда формалашачак:
• татар теле фәненә танып белү кызыксынуы;
• дәреслек геройларына һәм партадаш күршеңә ярдәм итү инициативасы;
• үз уңышларын/уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү;
• нормалардан тайпылышны күрү;

**Туган тел (татар теле) фәненнән көтелгән предмет нәтиҗәләре**
**Укучы белергә тиеш.**

| БҮЛЕК | 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| Фонетика һәм орфоэпия. Графика | Аваз һәм хәрефләрне аера; татар телендәге авазларга характеристика бирәбелә; сузык авазларның калын һәм нечкә, тартык авазларның яңгырау һәм саңгырау булуын белә;баш һәм юлхәрефләренең язылышын үзләштерә; аерым хәрефләрне, аларның кушылмаларын, иҗекләрне, сүзләрне, җөмләләрне графика, каллиграфия, гигиена кагыйдәләре таләп иткәнчә яза; әйтелеше язылышына туры | Татар алфавитын, андагы хәрефләрнең урнашу тәртибен белә, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру һәм кирәкле мәгълүматны эзләп табу өчен, алфавиттан файдаланырга өйрәнә. | Аваз һәм хәрефләрне аера;ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирергә өйрәнә;хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны кулланырга өйрәнә. | -аваз һәм хәрефләрне аера; -ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә ала; -хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитныкуллана ала |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | килгән сүзләрне ишетеп яза; хәрефләрне алфавит тәртибендә дөрес итеп әйтә. | | | |
| Сүз. Сүз төзелеше һәм ясалышы | Сүзнең мәгънәгә ия булуы өчен авазларның билгеле тәртиптә урнашуын аңлый;сүзләрне авазларга тарката, авазларны сүздәге тәртиптә әйтә белә. | Сүзләрнең тамырын билгели; төрле сүз төркемнәрен ясаучы кушымчаларны таба һәм күрсәтә; тамырдаш сүзләрне сүз формаларыннан аера белә | Кушымчаларның төрләрен (сүз ясагыч һәм сүз төрләндергеч кушымчалар), сүз формаларын һәм яңа сүзләр, аларның ясалышын чагыштырырга өйрәнә. | -тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларын аерырга; сүзнең тамыр һәм кушымчаларын (аффиксларын) табарга өйрәнә |
| Морфология | Предметны ,аның эшен, хәрәкәтен, төрле билгеләрен атаган сүзләрне аера белә. | Предметны, билгене, эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләрне, сорауларын үзләштерә. | Исемнәрне ң сан, килеш тартым белән төрләнеше н; сыйфатларның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләрен; фигыльнең лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнә. | -исемнәрнең сан, килеш һәм тартым белән төрләнешен; -сыйфатларның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләрен; -фигыльнең лексик- семантик үзенчәлекләрен өйрәнә. |
| Орфография һәм пунктуация | Сүзләрне юлдан- юлга күчерә белә; җөмләдәге сүзләрне аерып яза белә; җөмлә башында һәм ялгызлык исемнәрдә башхәреф яза белә; тактадан һәм китаптан текстны дөрес итеп күчереп яза белә; дөрес язу кагыйдәләрен өйрәнелгән күләмдә куллана белә; өйрәнелгән дөрес язу | Сүзнең дөрес язылышын орфографик сүзлектән карап билгели; 8-13 сүзле текстны хатасыз итеп күчереп яза; үзе язган яки бирелгән тексттагы орфографикһәм пунктуацион хаталарны таба һәм төзәтә. Өйрәнелгән дөрес язу кагыйдәләренә туры килгән 20-25 сүзле текстны укытучы әйтеп торганда яза. | Дөрес язылыш кагыйдәләрен өйрәнгән күләмдә кулланырга; сүзләрнең дөрес язылышынорфографик сүзлек буенча ачыкларга; 60–65 сүзле текстны дөрес итеп күчереп язарга; өйрәнелгән дөрес язу кагыйдәләренә туры килгән 55- 60 сүзле текстны укытучы әйтеп торганда язарга; үзе төзегән һәм тәкъдим ителгән текстны | -дөрес язылыш кагыйдәләрен өйрәнгән күләмдә кулланырга; -сүзләрнең дөрес язылышын орфографик сүзлек буенча ачыкларга; -80–90 сүзле текстныдөрес итеп күчереп язарга; -өйрәнелгән дөрес язу кагыйдәләренә туры килгән 70–80 сүзле текстны укытучы әйтеп торганда язарга; -үзе төзегән һәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кагыйдәләренә туры килгән 10-15 сүзле текстны укытучы әйтеп торганда яза белә. | | тикшерергә, орфографик һәм пунктуацион хаталарны табарга һәм төзәтергә өйрәнә. | тәкъдим ителгән текстны тикшерергә, орфографик һәм пунктуацион хаталарны табарга һәм төзәтергә өйрәнә. |
| Синтаксис | Җөмлә һәм текстны, сүзтезмә һәм сүзләрне аера белә; тексттан җөмләләрне аерып ала белә; җөмләләрнең схемасын, схемаларга туры килгән җөмләләрне аера белә; сүзләрдән җөмләләр төзи белә; схемалар, рәсемнәр буенча җөмләләр төзи белә; җөмлә башында баш хәреф, җөмлә ахырында нокта куя белә. | Җөмлә,җөмләләрнең әйтү максаты буенча төрләрен (хикәя, боеру, тойгылы, сорау) билгели; җөмләдәге тойгылы һәм тойгысыз интонацияне аера; җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен таба белә. | Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга; сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга; җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга; җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә; тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә өйрәнә. | -җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга; -сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга; -җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга; -җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә; -тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә өйрәнә. |
| Бәйләнешле сөйләм | Аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайлый белә; көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбеформаларын дөрес куллана белә; тәкъдим ителгәннәр арасыннан текстка исем сайлый белә; бирелгән җөмләләрдән текст төзи белә; сорауларны тыңлый, | Бәйләнешле сөйләмдә җөмләләрнең үзара бәйләнешен күрә, бер темага берләштерелмәгән аерым җөмләләрне текст белән чагыштыра, текстның темасын билгели белә. Текстагы кисәкләргә бүлә. Зур булмаган текстларга һәм текст кисәкләренә исем куя. Укыган әсәрнең эчтәлеген | Аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга; көндәлек аралашуга бәйлетатарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес кулланырга; аралашу ситуациясен исәпкә алып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә; текстка исем бирергә; | -аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга; -көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрескулланырга; -аралашу ситуациясен исәпкә алып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә; -текстка исем бирергә; - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | аңлый, дөрес җавап бирә белә. | сөйли. | укылган яки тыңлаган текстның планын төзергә; бирелгән тема буенча текстлар язарга өйрәнә. | укылган яки тыңлаган текстның планын төзергә; - аерым аралашу ситуацияләренә туры китереп, хат яки тәбрикләү хаты кебек кечкенә текстлар язарга өйрәнә. |

## УКУЧЫГА ҮЗЛӘШТЕРҮ МӨМКИНЛЕГЕ БИРЕЛӘ

| БҮЛЕК | 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| Фонетика һәм орфоэпия. Графика | Сүзлектән карап, сүзнең язылышын ачыкларга; аваз һәм хәреф саны туры килмәү очракларын билгеләргә | Сүзлектән карап, сүзнең язылышын ачыклый; сүзләргә фонетик-график (аваз-хәреф) анализы ясый, дәреслектәге үрнәк буенча сүзләрне мөстәкыйль рәвештә тикшерә һәм аның дөреслеген дәлилли белергә; дәреслектә бирелгән материал күләмендә укучы үзенең һәм әңгәмәдәше сөйләмендә татар әдәби теле | Дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча сүзгә мөстәкыйль рәвештә фонетик- график (аваз-хәреф) анализ ясый, сүзгә ясалган фонетик- график анализның дөреслеген бәяли ; сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба , яки укытучысына һәм әти-әнисенә мөрәҗәгать итә белә. | Укучыга дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча сүзгә мөстәкыйль рәвештә фонетик-график (аваз-хәреф) анализ ясарга өйрәнү, сүзгә ясалган фонетик-график анализның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге бирелә. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | нормаларын саклый белергә. | | |
| Сүз. Сүз төзелеше һәм ясалышы | Сүзнең мәгънәсен тануда сүз басымының әһәмиятен аңларга. | Дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачык күренеп торган сүзләрнеңтөзелешен тикшерүне һәм аның дөреслеген бәяләүне белергә. | Укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачыккүренеп торган сүзләрнең төзелешен тикшерү һәм аның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге ала. | Укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачык күренеп торган сүзләрнеңтөзелешен тикшерү һәм аның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге ала. Мәгънәле кисәкләренең чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен дәреслектә бирелгән күләмдә тикшерә (тартымын, булса, ясагыч кушымчаларын, нигезен билгели); сүзнең дөрес тикше релүен бәяли белә. |
| Морфология | Тәкъдим ителгән тексттан өйрәнелгән сүз төркемнәрен табарга. | Зат алмашлыклары, кайбер рәвешләр, бәйлекләр турында мәгълүмат ала белергә; | Укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча исемгә, сыйфатка, фигыльгә морфологик анализ ясый һәм аның дөреслеген бәяләү, тексттан алмашлык, рәвеш, бәйлек сүзләр, кисәкчә, теркәгечләрне, фигыльләрдәге юклык кушымчаларын (-ма / -мә) табу мөмкинлеге ала. | Өйрәнелгән сүз төркемнәренә дәреслектә бирелгән материал күләмендә морфологик анализ ясый, аның дөреслеген бәяли; |
| Орфография һәм | Орфографик хата | Орфограммага туры | Орфографик хата ясау | Укучы орфографик хата ясау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| пунктуация | җибәрү ихтимады булган урынны ачыкларга; э,о,ө,й,е,ю,я, к,г хәрефләре, йө,йо кушылмалары булган сүзләрне дөрес язарга;сүзләрне орфоэпик укыганда, әйтелеше һәм язылышы туры килмәү очракларын билгеләргә | килгән мисалларны сайлый; текст төзегәндә, орфографик һәм пунктуацион хаталар җибәрмәслек итеп яза ала белергә. | мөмкинлеге булган очракларны аңлау, аерым орфограммаларга мисаллар сайлау, текстлар төзегәндә орфографик һәм пунктуацион хаталарны булдырмау өчен, язганнарны үзгәртү, хаталар өстендә эшләгәндә, аларның сәбәпләренә төшенү һәм алдагы язма эшләрдә хата җибәрмәү юлларын ачыклау мөмкинлеге ала | мөмкинлеге булган очракларны аңлау, аерым орфограммаларга мисаллар сайлау, текстлар төзегәндә орфографик һәм пунктуацион хаталарны булдырмау өчен, язганнарны үзгәртү, хаталар өстендә эшләгәндә, аларның сәбәпләренә төшенү һәм алдагы язма эшләрдә хата җибәрмәү юлларын ачыклау мөмкинлеге ала. |
| Синтаксис | Укытучы ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәгесүзләр арасындагы бәйләнешне табарга; җөмләләрнең мәгънәви-интонацион үзенчәлекләрен күзәтергә. | Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аера; сораулар ярдәмендәсүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне таба; җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аера; җөмләнең баш кисәкләрен таба белергә. | Укучы җөмләнең иярчен кисәкләрен – аергыч, тәмамлык,хәлләрне аеру,дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча гади җөмләгә синтаксик анализ (җөмлә кисәкләре буенча) ясау һәм аны тикшерүнең дөреслеген бәяли, гади һәм кушма җөмләләрне бер-берсеннән аера белә. | Укучы җөмләнең иярчен кисәкләрен – аергыч, тәмамлык,хәлләрне аеру,дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча гади җөмләгә синтаксик анализ (җөмлә кисәкләре буенча) ясау һәм аны тикшерүнең дөреслеген бәяләү, гади һәм кушма җөмләләрне бер-берсеннән аеру мөмкинлеге ала. |
| Бәйләнешле сөйләм | Рәсем буенча 2-3 җөмләдән торган хикәя төзи һәм | Аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сөйләмне куллана һәм | Тәкъдим ителгән исемнең эчтәлегенә туры килгән текст төзү, бирелгән | Укучы тәкъдим ителгән исемнең эчтәлегенә туры килгән текст төзү, бирелгән текстның |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
